ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 179 от « 17 » 08 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы җирле
үзидарә органнарында остазлык турында
Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 7 октябрендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә остазлык турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1296 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 октябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында остазлыкны оештыру турында» 978 номерлы карары нигезләмәләре нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының яшь муниципаль хезмәткәрләрендә һөнәри белемнәр, аларның вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәүләрен булдыру, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтне узу үзенчәлекләре белән таныштыру максатында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә җирле үзидарә органнарында остазлыкны гамәлгә ашыру эшен оештырырга, остазлык гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәткәрләрне ачыклауны һәм аларга остазлар билгеләүне тәэмин итәргә, остазлык нәтиҗәләрен тикшереп торуны һәм бәяләүне гамәлгә ашырырга.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында остазлык турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә әлеге Нигезләмәдә каралган очракларда остазлык гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәткәрләрне билгеләүне һәм аларга остазлар билгеләүне тәэмин итәргә, нәтиҗәләрне тикшереп торуны һәм бәяләүне гамәлгә ашырырга.
4. Әлеге боерыкның үтәлеше буенча җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесен билгеләргә.

Муниципаль
район Башлыгы А.П. Иванов

000178